ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяда «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяда:

а) 1 пунктта «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрындагы» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы» сүзләренә алмаштырырга;

3) $32^1$ статьяда:

а) 8 пунктта «күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры» сүзләренә алмаштырырга;

б) 17 пунктта:

1 пунктчада «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктчада «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 41 статьяның 2 пунктында «күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы орган» сүзләрен «хокукларны теркәү органы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 47 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47 статья. **Җир өлешенә хокукны таныклаучы документлар**

«Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон үз көченә кергәнче җир өлешләренә хокук турында бирелгән таныклыклар, ә алар булмаганда, күрсәтелгән Федераль закон үз көченә кергәнче кабул ителгән, авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен хосусыйлаштыру турында җирле үзидарә органнарының җир өлешенә хокукларны таныклый торган карарларыннан өземтәләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы язмалар белән бер үк юридик көчкә ия була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 10 июль
№ 52-ТРЗ